**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2020 ел, 20 гыйнвар №184

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозулар кылган өчен җаваплылыгы турындагы нигезләмәнең 1.3 пунктына үзгәрешләр кертү хакында**

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге Советының 2012 елның 30 ноябрендә кабул ителгән 39 номерлы «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында» гы карарына кушымтага Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Биеш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең коррупцион хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итергә:

1.3. Дисциплинар җәзаларны куллану һәм бетерү тәртибе, хезмәт законнары белән билгеләнә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Биеш авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р. А. Вәлиев**